БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
1 июнь 2026 ел

**КАРАР**
№55

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану Тәртибенә үзгәреш кертү турында**

Балтач районы прокурорының 2026 елның 29 апрелендәге 02-08-01-2026/Прдп152-26-20920011 номерлы протестын карап, Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар кабул итте:**

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль юл фондын булдыру турында» Балтач район Советының 2013 елның 5 ноябрендәге 189 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль юл фонды бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллану Тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Юл фонды бюджет ассигнованиеләре күләме Татарстан Республикасы Балтач муниципаль район Советының чираттагы финанс елына һәм план чорына җирле бюджет турында карары белән җирле бюджет керемнәренең фаразлана торган микъдарыннан ким булмаган күләмдә раслана:

Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына, эшкәртелмәгән бензинга, дизель ягулыгына, дизель һәм (яисә) карбюратор (инжектор) двигательләр өчен мотор майларына җирле бюджетка күчерелергә тиешле акцизлардан керем;

җирле бюджетларның транспорт салымыннан керемнәре (әгәр Россия Федерациясе субъекты законы белән җирле бюджетларга транспорт салымыннан чигерүләрнең бердәм нормативлары билгеләнгән булса);

җирле бюджетларның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөк транспорт чаралары китергән зыянны компенсацияләү исәбенә түләүдән керемнәре;

җирле бюджетларның авыр йөк һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасы хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен штрафлардан керемнәре;

җирле бюджетка муниципаль берәмлекнең муниципаль юл фондын булдыруны күздә тоткан вәкиллекле органы карары белән расланган башка кертемнәр.

«муниципаль юл фондының бюджет билгеләнмәләре күләме чираттагы финанс елында җирле бюджетның әлеге пунктта күрсәтелгән керемнәренең хисап финанс елында фактта кергән һәм аны формалаштыру вакытында фаразланган күләме арасындагы аерманы исәпкә алып төзәтелә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Балтач муниципаль район Башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин